Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы
КАРАРЫ

17 август 2022 ел №60

Түбән Мактама бистә Советының 2012 елның 27 декабрендәге 119 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә. 2022 елның 27 июнендәге 4 номерлы ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне күздә тотып («Альметьевский вестник» газетасының 2012 елның 21 июлендәге 29 номерлы басмасы)

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:


1. Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2012 елның 27 декабрендәге 119 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында махсус билгеләнештәге яшелләндерүнең территориаль зонасын (СН3), перспективалы төзелеш зонасын (Ж1П) киметергә һәм Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Түбән Мактама ш.т.б., Промышленная урамы адресы буенча 16:45:070101:84 кадастр номеры булган җир кишәрлегенә карата V класслы куркынычлылык җитештерү-коммуналь объектларның территориаль зонасын (П-5) билгеләргә.

Гамәлдәге торышы




Кертелгән үзгәрешләр



2. Әлеге карарны Түбән Мактама ш.т.б. һәм Тихоновка торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама ш.т.б. башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов